КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 926

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче; 2017 ел, 23 июнь, 417 нче; 2018 ел, 14 июнь, 472 нче; 2019 ел, 13 июнь, 487 нче; 2019 ел, 2 сентябрь, 748 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «3. | Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар йөртү һәм багаж ташу буенча эшчәнлекне тормышка ашыру өчен рөхсәт бирү һәм яңадан рәсмиләштерү, дубликатын бирү»; |

түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы», «Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе», «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» бүлекчәләрен өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | |
| 1. | Татарстан Республикасы милкендә булган җирләрдән җир кишәрлеге бирүне алдан килештерү |
| 2. | Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен физик яки юридик затларга сатулар үткәрмичә генә арендага яки милеккә бирү |
| 3. | Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү |
| 4. | Татарстан Республикасы милкендә булган җир кишәрлекләрен даими (сроксыз) файдалануга бирү |
| 5. | Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү |
| Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе | |
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сатуга һәм алкогольле продукцияне ваклап сатуга лицензияне яңадан рәсмиләштерү |
| Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты | |
| 1. | Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетын бирү һәм гамәлдән чыгару». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин